КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 20 июль г.Казань № 616

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Аксубай һәм Нурлат муниципаль районнары территориясендә амброзия (амброзия трехраздельная) буенча карантин кертү турында» 2007 ел, 19 июль, 312 нче;

«Аксубай, Менделеевск, Нурлат һәм Чистай муниципаль районнары территориясендә карантинлы чүп үләннәре һәм корткычлар буенча карантин кертү турында» 2009 ел, 12 октябрь, 711 нче;

«Чистай муниципаль районы территориясендә кыр чормавыгы буенча карантин кертү турында» 2011 ел, 15 октябрь, 851 нче;

«Нурлат муниципаль районының кайбер территорияләрендә амброзия (амброзия трехраздельная) буенча карантинны бетерү турында» 2012 ел, 26 гыйнвар, 46 нчы;

«Югары Ослан муниципаль районы территориясендә бәрәңге нематодасы (йомры суалчаннары) буенча карантин кертү турында» 2012 ел, 3 ноябрь, 943 нче;

«Әтнә һәм Нурлат муниципаль районы территориясендә бәрәңге нематодасы (йомры суалчаннары) буенча карантин кертү турында» 2013 ел, 19 август, 573 нче;

«Әлки муниципаль районы территориясендә бәрәңге нематодасы (йомры суалчаннары) буенча карантин кертү турында» 2013 ел, 20 август, 578 нче;

«Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә бәрәңге йомры суалчаннары буенча карантин кертү турында» 2013 ел, 20 сентябрь, 672 нче;

«Минзәлә һәм Менделеевск муниципаль районнары территорияләрендә бәрәңге йомры суалчаннары буенча карантин кертү турында» 2014 ел, 29 июль, 554 нче;

«Менделеевск муниципаль районы территориясендә амброзия (амброзия трехраздельная) һәм Европа кычыткан ефәге буенча карантинны бетерү турында» 2014 ел, 30 июль, 557 нче;

«Әлмәт муниципаль районы территориясендә кыр чормавыгы буенча карантинны бетерү турында» 2014 ел, 25 октябрь, 779 нчы;

«Тукай муниципаль районының аерым территорияләрендә бәрәңге йомры суалчаннары буенча карантин кертү турында» 2014 ел, 3 декабрь, 942 нче;

«Спас муниципаль районының аерым территориясендә бәрәңге нематодасы (йомры суалчан) буенча карантин кертү турында» 2014 ел, 23 декабрь, 1013 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин